| | |
|---|---|
| СОВЕТ КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| ул.Гагарина, д.29, с.Куюк-Ерыкса, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422151 | Гагарин ур., 29 нче йорт, Көек-Ерыкса авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422151 |

тел.(факс): (85563) 3-66-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

| | |
|---|---|
| Решение | Карар |
| « 15 » май 2017 ел | № 2-20 |

## Мамадыш муниципаль районының Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советының 2011 елның 30 мартындагы «Мамадыш муниципаль районының Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясендә терекөмешле калдыкларны җыю, алып китү, утильләштерү һәм эшкәртү тәртибен раслау турында» 4-4 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Мамадыш районы прокурорының 2017 елның 15 мартындагы җитештерү һәм куллану калдыклары турында законнарны бозуларны бетерү турында №02-08-03-2017 номерлы күрсәтмәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советының 2011 елның 30 мартындагы «Мамадыш муниципаль районының Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясендә терекөмешле калдыкларны җыю, алып китү, утильләштерү һәм эшкәртү тәртибен раслау турында» 4-4 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып игълан итәргә.
3. 3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге башлыгы Ф.Р.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советы рәисе /Ф.Р.Шәйхетдинов/